ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» 2021 елның 5 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 пунктына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 36 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4) органик продукция җитештерүчеләр – органик продукция җитештерүне, саклауны, маркировкалауны, транспортировкалауны һәм реализацияләүне гамәлгә ашыра торган һәм органик продукция җитештерүчеләрнең бердәм дәүләт реестрына кертелгән юридик һәм физик затлар, чит ил юридик затлары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар.».

## 2 статья

Әлеге Закон 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 59-ТРЗ